| | |
|---|---|
| Республика Татарстан Совет<br>Абалачевского сельского поселения<br>Менделеевского муниципального района<br>Республики Татарстан | Татарстан Республикасы Менднлеев<br>муниципаль районы<br>Абалач авыл<br>Җирлеге Советы |

| | |
|---|---|
| Решение<br>2020 елның 9 июленнән | Карар<br>№ 140 |

Менделеевск муниципаль районының
2016 елның 23 мартыннан
20 нче номерлы Абалач авыл җирлеге
карарына үзгәрешләр кертү турында

Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексының 18 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге Уставы белән Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлеге Советы КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Абалач авыл җирлеге Советының 2016 елның 23 мартындагы 20 номерлы карары “Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүне дәгъвалаучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында нигезләмә” белән расланган Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүгә дәгъва кылучы гражданнар тарафыннан керемнәр, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру, шулай ук Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районының Абалач авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар тарафыннан керемнәр, чыгымнар, мөлкәт һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләр турында белешмәләр тапшыру хакында Нигезләмәгә киләсе үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 5 пунктын үзгәртергә һәм түбәндәге редакциядә бәян итәргә
«5. Тиешле исемлеккә кертелгән муниципаль хезмәт вазыйфасын биләүче муниципаль хезмәткәр үзенең чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти

характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр тапшыру өчен билгеләнгән тәртиптә һәм форма буенча белешмәләр тапшырырга тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында http://mendeleevsk.tatarstan.ru «Абалач авыл җирлеге» бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Абалач авыл җирлеге
Советы Рәисе И.Ш. Исрафилов